Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
Өстәмә профессиональ белем бирүче
дәүләт автоном мәгариф оешмасы
“Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты”

# ИЗЛОЖЕНИЕ ЯЗУГА ӘЗЕРЛЕК

татар теле һәм әдәбияты буенча башлангыч гомуми һәм төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә куючы педагогик хезмәткәрләр өчен методик ярдәмлек

КАЗАН
2016

**БКК 74.268.1 Тат**
**И 36**

**Автор-төзүче:**
Мозаффарова Мингаян Гаязовна, милли мәгариф лабораториясенең өлкән методисты, педагогика фәннәре кандидаты.

Изложение язуга әзерлек: татар теле һәм әдәбияты буенча башлангыч гомуми һәм төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә куючы педагогик хезмәткәрләр өчен методик ярдәмлек / авт.-тез. М.Г.Мозаффарова. – Казан: ТРМҮИ. – 35 б.

*Әлеге хезмәт төп гомуми белем бирүнең нәтиҗәлелеген – сыйфат күрсәткечен ачыклау формасы буларак Изложение жанры белән оештырылырга тиешле эшчәнлек асылын кассызыклауга багышлана.*

*Татар теле һәм әдәбияты буенча башлангыч һәм төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә куючы педагогик хезмәткәрләргә адреслана.*

© ТРМҮИ, 2016

# ИЗЛОЖЕНИЕ ЯЗУГА ӘЗЕРЛЕК

*Изложение* гомуми белем бирү оешмаларында актив кулланышка кергән язма эш төрләренең (диктант, сочинение кебек**)** берсе.

Рус теленең аңлатмалы сүзлегендә [3, 240] мәктәп жанры буларак **“**изложение” гә мондый аңлатма бирелә:

*1) изложить* – описать, передать устно или письменно;

2) то, что изложено, высказано или написано;

3) письменное упражнение, перелагающее содержание прочитанного и услышанного.

Әлеге билгеләмәләрдән күренгәнчә, Изложение укучы шәхесенең коммуникатив компетентлылыгы үсешен күрсәтүче әзер текстны бәян итә торган язма эш төре.

К**оммуникатив компетентлылык эчтәлеге**

“Коммуникатив компетентлылык” ның асылын – аны тәшкил итә торган компонентларны искә төшерик**.** Коммуникатив компетентлылык = сөйләм компетентлылыгы + тел гыйлемендә компетентлылык+ социаль- мәдәни компетентлылык+ танып белү компетентлылыгы**.**

Һәр компонентның эчтәлеген барлыйк.

**Сөйләм компетентлылыгы:**

- **диалогик сөйләм күнекмәсе** (сөйләмнең тәкъдим ителгән ситуациягә тәңгәллеге; реактивлык – куелган сорауны аңлый һәм үзвакытлы реплика белдерә; апеллятивлык – әңгәмәдешенә социаль корректлы итеп җавап бирә, сөйләм үрнәкләрен урынлы куллана белүе; коммуникабльлек күнекмәсе – җавап биреп кенә калмый, ә әңгәмәгә яңа төсмер, яңа сюжет кертеп җибәрә ала);
- **монологик сөйләм күнекмәсе:** (исендә калган сүзләрне, җөмләләрне урынлы куллана; грамматик конструкцияләрдән файдаланып жөмләләр төзи; сөйләм продуктивлыгы – үз фикерен татарча, әдәби тел нормаларына тәңгәл итеп, җиткерә ала);
- **ишетеп аңлау күнекмәсе** (перцевтив – моңарчы ишеткән текстны таный; аудиотексттагы төп фикерне аерып ала, аңлый**;** образлы итеп кабул итә ала, хәтердә тотрыклы саклый; эчке сөйләм белән әйтә ала);

- **аңлы уку күнекмәсе** (мәгълүматның яшерелгән мәгънәсен таба белү);
- **язма сөйләм күнекмәсе (**сорауларга язма җавап бирү, текстка карата сораулар әзерләү һәм язу, күчереп яки ишетеп язу);

**Тел гыйлемендә компетентлылык**: татар теленең үзенчәлекле авазларын, грамматик категорияләрен – җөмлә моделен, сүз ясалышы үзенчәлеген, сөйләм калыпларын үзләштерү дәрәҗәсе.

С**оциаль - мәдәни компетентлылык**: татар халкының мәдәниятын һәм гореф гадәтләрен белү, милли мәдәниятны мәдәниятлар яссылыгында карый белү.

**Танып белү компетентлылыгы:** анализ, синтез, абстракция, конкретлаштыру, гомумиләштерү, классификация ясау кебек фикерләү күнекмәләре; тыңлый һәм ишетү күнекмәләре үсеше.

Коммуникатив компетентлылык тел гыйлемен үзләштерү, кулланышка куя белү дәрәҗәсен асссызыклый. Менә ни өчен Изложение төп гомуми белем баскычын тәмамлаучы укучы өчен бердәм дәүләт имтиханы формасы булып тора.

## ИЗЛОЖЕНИЕ ТӨРЛӘРЕ

Изложение түбәндәге принципლардан чыгып классификацияләнә:

1) үткәрү максатына карап
- өйрәтү характерындагы
- контроль

2) текст материалына карап
- хикәяләү;
- тасвирлау;
- мөнәсәбәт белдерү, фикер йөртү (рассуждение);

3) эчтәлекне бирү характерына карап
- тулы, җентекле, текстка якын итеп

(текст тулысынча, бөтен нечкәлекләре белән бәян ителә, текстның композициясе һәм автор кулланган тел-сурәтләү чаралары тулысынча саклана; биредә текст эчтәлеге белән янәшә кулланылган тел-сурәтләү чаралары да тирән анализлана, аеруча

образлы гыйбарәләр язып куела һәм изложениедә кулланышка кертелә) бәян ителә;

- җыйнак, кыскартып (композициядәге детальләр төшерелеп, төп эчтәлек кенә) бәян ителә;
- сайлап (текст тулысынча түгел, ә ниндидер темага бәйле бер өлеше генә) бәян ителү;
- сочинение элементы белән яки иҗади биремле (бирелгән текстның эчтәлегенә яисә композициясенә билгеле бер үзгәрешләр кертелә).

## ӨЙРӘТҮ ХАРАКТЕРЫНДАГЫ ИЗЛОЖЕНИЕЛӘРНЕ ҮТКӘРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Текст белән танышу. Укытучы сәнгатьле итеп укый. Укучылар тыңлый, караламада шартлы тамгалар белән абзацларны, абзацтагы җөмләләр санын билгеләп баралар. Мисал өчен: z (абзац; ....! (бу абзацта 4 җөмлә, 3 се хикәя җөмлә, 4 нчесе тойгылы җөмлә). Текстның төзелеше (исеме, абзацлар, абзацларның сөйләмдә озын пауза белән белдерелүе хакында әңгәмә.

- Сүз-орфографик эш. Мөһим этап. Яңа сүзләр, аларның мәгънәсе, язылышы, кулланылу үзенчәлекләре үзләштерелү өчен җирлек тудырыла. Белем бирүдә федераль дәүләт стандартларының таләбе – укучының танып белү эшчәнлеген оештыру зарурлыгын истә тотсак, белешмә сүзлекләр белән эш оештырылырга тиеш була.
- Текстта сүзнең кем яки нәрсә турында баруы, төп фикере хакында парларда яисә төркемнәрдә, аннан соң төркемара әңгәмә оештырыла.

Эчтәлекне бирү характеры хакында сөйләшү оештырыла. Укытучы төгәл, ачык итеп эчтәлекне бирү характерын ассызыклый. Мисал өчен: Изложение язуның бүгенге максаты - текстны тулы, җентекле, текстка якын итеп бәян итү.

Эш ысулы – ничек? соравына җавап парларда яисә төркемнәрдә, аннан соң төркемара әңгәмәдә ачыклана, яисә искә төшерелә: текст тулысынча, бөтен нечкәлекләре белән бәян ителә, текстның композициясе һәм автор кулланган тел-сурәтләү

чаралары тулысынча саклана; биредә текст эчтәлеге белән янәшә кулланылган тел-сурәтләү чаралары да тирән анализлана, аеруча образлы гыйбарәләр язып куела һәм изложениедә кулланышка кертелү өчен җирлек тудырыла.

- Бергәләп план төзү – кече (микро) темаларны аерып алу. Бу эш парларда яисә төркемнәрдә оештырыла, аннан соң төркемара әңгәмәдән чыгып тактада һәм дәфтәрләрдә языла.
- Укытучы кабат укый, укучылар каләм һәм каралама белән тыңлыйлар; ишетеп кабул итәләр, теркиләр.
- Караламада изложение язу. Укытучы вакыт билгели. Һәркем мөстәкыйль эшли.
- Үзтикшерү. Укытучы вакыт билгели. Ихтыяҗ бар икән, белешмә сүзлекләрдән файдалану рөхсәт ителә, шартлар тудырыла.
- Дәфтәргә күчереп язу.
- Рефлексия: Изложение текстнын тулы, җентекле, текстка якын итеп бәян итү ничек башкарылды?

Парларда яисә төркемнәрдә ничек эшләүләре хакында сөйләшү оештырыла, аннан соң төркемара әңгәмәдән чыгып тактада һәм дәфтәрләрдә ысул теркәлә. Һәркем үз-үзенә, иптәшенә сөйләп карый.

**Искәрмә:** Өйрәтү характерындагы барлык төр изложениеләр дә шул рәвешле оештырыла.

**Планлаштырылган нәтиҗәлелек:** Укучының “изложение” дип аталган язма эш төрен башкару ысулын үзләштерүе, мөстәкыйль куллана алырга әзер булуы.

## КОНТРОЛЬ ИЗЛОЖЕНИЕЛӘРНЕ ҮТКӘРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ

1. Эчтәлекне бирү характеры хакында сөйләшү. Контроль эшнең максатын ассызыклау. Укытучы максатны аңлата. Укучылар игътибар белән тыңларга, ишетергә һәм эчтән генә ничек эшләргә кирген исләренә төшерергә тиеш була.
2. Текст белән танышу.

2.1.Укытучы сәнгатьле итеп 2 тапкыр укый.

2.2. Укучы мөстәкыйль рәвештә, укытучы искәртүен көтми генә, түбәндәге адымнарны башкара:

- игътибар белән тыңлый, текстның төзелешенә (исеме, абзацлар саны) әһәмият бирә – караламада шартлы тамгалар белән абзацларны, абзацтагы җөмләләр санын билгеләп бара;
- текстта сүзнең кем яки нәрсә турында баруын, төп фикерен тотып алырга тырыша; язылышы, яисә мәгънәсе ягыннан ачыкланырга тиешле лексик берәмлекне теркәп куя;

3. Укучы мөстәкыйль рәвештә, сүз-орфографик эш (сүзлек эше) башкара: үзе өчен сирәк очраган, үзенчәлекле сүзләрнең мәгънәсен, язылышын, кулланылу үзенчәлекләрен искә төшерә; ихтыяҗ бар икән, белешмә сүзлекләргә мөрәҗәгать итә.
4. Һәркем мөстәкыйль рәвештә план төзи – кече темаларны аерып алу.
5. Караламада изложение язу
6. Үзтикшерү.
7. Дәфтәргә күчереп язу.

Искәрмә: Укучы бирелгән вакытны да үзе чамаларга бурычлы: караламада язуга, үзтикшерүгә, дәфтәргә күчереп язуга кайчан керешәчәген үзе билгели белергә тиеш. Вакыт-кыйммәтле кыйммәт. Аны тоемлый, рациональ бүлә белү зарур.

**Планлаштырылган нәтиҗәлелек:** Укучының “изложение” дип аталган язма эш төрен мөстәкыйль башкару – “изложение” язу ысулын мөстәкыйль куллана белүе.

## ЯЗМА СӨЙЛӘМГӘ ӨЙРӘТҮ КАЙЧАН БАШЛАНА?

**(**“изложение” язуга әзерлек кайчан башлана**)**


Әлбәттә, язма сөйләмгә өйрәтү 1 нче сыйныфның беренче дәресләрендә үк, язу күнекмәсе формалаштыру чорында ук башлана. Язу күнекмәсе укучының укудагы өлгерешен тәэмин итүче иң мөһим гомумуку күнекмәләренең берсе. 1 нче сыйныфның I–III чирекләрендә базис уку планнары нигезендә атнага 3 сәгать язу дәресләре укытыла. Бу дәресләр “Татар теле” дәресенең башлангычы булып тора. Әлифба дәресләрендә балалар авазларны белдерүче хәрефләрне күреп танырга өйрәнә, ә язу дәресләрендә дөрес язарга өйрәнергә тиеш булалар. Язу дәресләренең асыл бурычы: ысул өйрәтү аша укучыда дөрес язу

күнекмәсе формалаштыру; фикерләүнең барлык төрләрен кулланышка алу аша язма сөйләм күнекмәсенә нигез салу.

Укытучы мәктәптә укучының уку эшчәнлеген максатка ярашлы итеп оештырырга бурычлы. Нәрсә соң ул «эшчәнлек»?

- «Эшчәнлек – Деятельность» – куелган максатка ирешү һәм барлыкка килгән ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен реаль чынбарлыкны үзгәртү процессы- это это процесс преобразования реальной действительности для достижения намеченной цели и удовлетворения возникшей потребности
- Эшчәнлек – танып белүгә һәм субъектның үз-үзен үзгәртүгә юнәлдерелгән психик активлык формасы. Эшчәнлекнең төрләре һәм сыйфат күрсәткечләре



Димәк, эшчәнлек ул – проблеманы (хәл ителергә тиешле мәсьәләне) аерып алу, аның чишү юлларын билгеләү, иң эффектив юлны аерып алу һәм чишү; рефлексия ясау (нәрсә эшләргә тиеш идем, ничек эшләдем, нинди нәтиҗәгә ирештем); үз эшеңә бәя бирү (максатка ирештемме, ни дәрәҗәдә? бу нәрсәдә күренә? ирешмәсәм ни өчен ирешмәдем? ничек төзәтеп була дип фикер йөртү).

Схемада күренгәнчә, эшчәнлекнен сыйфат күрсәткечләре төрле:

- репродуктив эшчәнлек (шаблон буенча эшләү);
- конструктив эшчәнлек (репродуктив эшчәнлек аша үзләштерелгән белем һәм күнекмәләрне яңа шартка, яңа җирлеккә күчерә белү);
- иҗади эшчәнлек (репродуктив һәм конструктив эшчәнлек аша үзләштерелгән белем һәм күнекмәләрне теләсә нинди шартларда һәм җирлектә куллана белү күнекмәсе).

Иҗади фикер – болай була, болай була, башкача булмыймы икән, дип уйлый белү. Иҗади гамәл- болай була, болай була, менә болай эшләсәм ничек булыр икән, дип уйлап, башкача гамәл кылу.

Белем бирүдә федералҗ дәүләт стандартларын гамәлгә куюда укытучының иң мөһим бурычы – укучыларның иҗади уку эшчәнлеген оештыру. Димәк, укытучы нинди өлкәдә танып белү процессы оештыруына карамастан, проблеманы (хәл ителергә тиешле мәсьәләне) аерып алуны, аның чишү юлларын билгеләүне, иң эффектив юлны аерып алу һәм чишүне; рефлексия ясауны (нәрсә эшләргә тиеш идем, ничек эшләдем, нинди нәтиҗәгә ирештем); үз эшеңә бәя бирүне (максатка ирештемме, ни дәрәҗәдә? бу нәрсәдә күренә? ирешмәсәм ни өчен ирешмәдем? ничек төзәтеп була дип фикер йөртү) оештырыга тиеш.

Иҗади уку эшчәнлеге оештыру аша укучыда үз-үзен үстерү күнекмәсе формалашу, автоматлашу цчен ьирлек тщэмин итщргэ бурычлы.

Язу күнекмәсе укучының укудагы өлгерешен тәэмин итүче иң мөһим гомумуку күнекмәләренең берсе. Язу дәресләренең асыл бурычы: ысул өйрәтү аша укучыда дөрес язу күнекмәсе формалаштыру; фикерләүнең барлык төрләрен кулланышка алу аша язма сөйләм күнекмәсенә нигез салу. Мәгълүмати технологияләр тормышыбызның барлык өлкәләрен яулаган чорда бүгенге укучы


бәлки киләчәктә ручка белән язып утырмас – компьютердан файдаланыр. Әмма язу дәресләрендә дә укучы эшчәнлеген заман таләпләренә җавап бирерлек оештыру һәм бирелгән вакытны нәтиҗәле кулланышка кертү зарур. Бу – бәхәссез...

Сүзебез укучыда язу күнекмәсен формалаштыруга юнәлтелгән эшчәнлек оештыру хакында булыр.

Мәгълүм булганча, теләсә кайсы эшчәнлекнең диагностикага нигезләнүе зарур.

## БАЛАЛАРНЫҢ ЯЗУГА ӘЗЕРЛЕГЕН ТИКШЕРҮ МЕТОДИКАСЫ

Бу тест С.О.Филиппова һәм О.А.Каминскийлар тарафыннан эшләнгән. Безнең фикеребезчә, бу тест эффектив. Чөнки, беренчедән, әле язарга өйрәнмәгән балалар өчен кыенлык тудырмый; икенчедән, укытучыдан күп вакыт сарыф итүне таләп итми; өченчедән, тест фәнни эзләнүләр, тикшерүләр нәтиҗәсенә нигезләнгән.



Тест барлык балалар белән дә бер үк вакытта, дәрестә үткәрелә. Аларга эш техникасы аңлатыла, максат әйтелә.

Укытучы «башладык!» диюгә укучы укытучы биргән темпта «елгачык ярларын» тоташтыручы «күперләр» сала - схемада күрсәтелгән дулкынлы ике кара сызыкны, шашмакларның вертикаль сызыклары буйлап, өстән аска тоташтыра башлый.

Темп 2 секунд белән билгеләнә. Ягъни укытучы 2 секунд саен сигнал бирә. Мисал өчен, санау сигнал була ала.

Мәсәлән:

| укытучы | укучылар |
|---|---|
| «әзерләндек» | → ручкаларны алалар |
| «башладык» | → психологик әзерленеп сигнал көтәләр |

| | |
|---|---|
| «бер» | → өстән аска таба 1 «күпер» салына |
| ике секундтан соң «ике» | →2 нче күперне салалар |
| шул рәвешле 30 га кадәр саный | → кемдер укытучыга иярәчәк, кемдер юк... |
| «30» ди һәм 2 секунд көтә →ручкаларны куярга куша | →ручкаларын куялар |

**Тест 5 балл системасында бәяләнә**

| | |
|---|---|
| 5 балл «бишле» | - 29-30 «күпер» туры итеп һәм «ярларның теге ягына чыкмыйча» салынган |
| 4 балл («дүртле») | а) 29-30 «күпер» салынган, әмма сыйфат бик яхшы түгел, «күперне», «ярларның теге ягына ук» чыгарып салган урыннар бар;<br>б) 24 «күпер» генә, әмма сыйфат бик яхшы |
| 3 балл («өчле») | а) 29-30 «күпер», ә сыйфат начар «күперләр» кәкре-бөкре, ярларның теге ягына чыккан урыннар шактый;<br>б) 13-15 «күпер» генә, әмма сыйфат бик яхшы, хатасыз |
| 2 балл («икеле») | а) 29-30 «күпер» салынган әмма бик зур хаталар белән;<br>б) 7-10 «күпер» салынган, һәм эш бик сыйфатлы |
| 1 балл («икеле») | «күперләр» бик аз һәм бик зур ялгышлар белән. |

Үзбәя куюю эше оештырыла:

| укытучы | укучылар |
|---|---|
| һәркем үз «күперләрен» санасын | саныйлар |
| 29-30 «күпер» салучылар бассын әле | басалар |
| баскан укучылар үз эшләрен игътибар белән карасын һәм мине игътибар белән тыңлап, үзенә тиешле бәяне сайласын; критерийларның пунктлары һәм адекват бәя әйтелә | үзләренә тиешле бәяне «балл»ны сайлыйлар:<br>«5» яшел түгәрәк<br>«4» зәңгәр<br>«3» кызыл |

| | |
|---|---|
| яшел түгрәк алучылар баса;<br>(Тактаның бер почмагына яза бара:<br>5 балл - а)- укучы б)- укучы<br>4 балл а)- укучы б)- укучы<br>3 балл а) - укучы б) - укучы<br>1 балл | шул рәвешле үзбәя куела (укытучы һәркемгә булыша) |

## ИШЕТЕП (ДИКТАНТ) ЯЗУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ ФОРМАЛАШТЫРУ

Эшчәнлекне график диктантлар язудан башлау мөһим. (Бу эш математикада да беренче дәресләрдә үк оештырыла; мәсәлән: «дәфтәр битенең өске өлешендә, сул ягыннан ике шакмак, өстән 2 шакмак калдырып нокта куегыз, ноктадан аска таба 3 шакмак төшеп тагын нокта куегыз, хәзер ике ноктаны тоташтырыгыз...» һ.б.

Язу дәресләрендә күнекмәләр Әлифба дәресләрендә үзләштерелгән белем һәм күнекмәләрне язуда күрсәтү аша формалаштырыла. Ягъни сүзләрне, сүзләрне тәшкил итүче авазларны шартлы билгеләр белән язуда күрсәтү. Укучы күпкырлы эшчәнлек алып бара: тыңлый → ишетә → биремгә җавап әзерли →телдән (үз-үзенә) әйтә → яза. Эш тәмамлангач чагыштырып (укытучы үрнәге белән) үз эшен тикшерә, бәяли.

**График диктант.**

**Максат:** Предметны, предметның эшен, билгесен белдергән сүзләрне ишетеп шартлы билгеләр белән язуда күрсәтү күнекмәсе формалаштыру.

| Укытучы | Укучылар |
|---|---|
| кош | ——————— |
| сайрый | ======== |
| кызыл | ~~~~~~~~ |
| агач | ——————— |
| тәмле | ~~~~~~~~ |

Бәяләү критерийсы:

| Билге | Белем | Балл | Язу күнекмәсе | Балл |
|---|---|---|---|---|
| «5» | 5 сүз дә дөрес | 5 | 8-10 тамга төгәл | 5 |
| «4» | 4 сүз дөрес | 4 | 6-7 тамга төгәл | 4 |
| «3» | 3 сүз дөрес | 3 | 4-5 тамга төгәл | 3 |
| «2» | 2 сүз дөрес | 2 | 3-0 тамга төгәл | 2 |

Искәрмә. Язу күнекмәсен бәяләү механизмы түбәндәгечә:

Укучы 10 тамга элементы яза

▭ - 5; ———— - 2; ======== - 1; ~~~~~~~~ - 2.

Һәр элемент 0,5 балл белән бәяләнә. Максималь балл - 5.

**График диктант.**

**Максат:** Ишеткән сүзләрне авазларның шартлы билгеләре (тартык – ☐; сузык – ○) белән язуда күрсәтү күнекмәсе формалаштыру.

Күләм: 2-3 аваздан торган 3-4 сүз.

| Укытучы | Укучылар |
|---|---|
| каз | ☐○☐ |
| ат | ○☐ |
| боз | ☐○☐ |
| өй | ○☐ |

Искәрмә: Ысул өйрәтелә: Сүзне тулысынча әйтәм → һәр авазны аерым-аерым «тотып» тамгасын язам.

Бәяләү:

| | Белем | Язу күнекмәсе | |
|---|---|---|---|
| Билге | Критерий | Критерий | Балл |
| «5» | 10 аваз дөрес | 8-10 тамга дөрес | һәр тамгага 1 балл (8-10) |
| «4» | 8-9 аваз дөрес | 6-7 тамга дөрес | “-“ (6-7) |
| «3» | 4-7 аваз дөрес | 4-5 тамга дөрес | “-“ (4-5) |
| «2» | 3-1 аваз дөрес | 3-0 тамга дөрес | “-“ (3-0) |

**График диктант**

**Максат:** Ишеткән сүзләрне тартык һәм сузык авазларның шартлы билгеләре белән күрсәтү, «сүзләр» арасына өтер кую күнекләсе формалаштыру.

Укытучы: Ат, бал, туп, аш, он.

Укучылар: ○□, □○□, □○□, ○□, ○□.

Бәяләү:

| Белем | Язу күнекмәсе |
|---|---|
| «5» - 5 сүз дә дөрес язылган | 4 өтер, 1 нокта, 5 «○», 7 «□»дөрес язылса, урнаштырылса |
| «4» - 4 сүз дөрес язылган | 3 өтер, 1 нокта, 4 «○», 5, 6 «□» дөрес язылса, урнаштырылса |
| «3» - 3 сүз дөрес язылган | 2 өтер, 1 нокта, 3 «○», 4 «□» дөрес язылса, урнаштырылса |
| «2» - 2-0 сүз дөрес язылган | калган очракта |

Искәрмә: укучы 17 элемент яза: ○ - 5; □ - 7; « , » - 4; « . » - 1.

**График диктант**

**Максат:** Өйрәнелгән элементлар кушылмаларын ишетеп язу, өтер кую күнекмәләрен формалаштыру**.**

Укытучы: Хәзер без өйрәнгән элементларны искә төшереп, ишетеп язарбыз. Моның өчен мин элементларны әйтеп чыгам, сез игътибар белән тыңлыйсыз һәм элементларны күз алдына китерәсез. Аннан соң беренче элементны мин әйтәм, ә сез язарсыз, мин кабат әйтермен, сез дөреслеген тикшерерсез; беренче элементны кызыл юлдан язарга, элементлар арасына өтер, соңыннан нокта куерга.

Әзерләндек:

1) асты йомры ыргаклы кечкенә авыш туры сызык;
2) өсте элмәкле азын авыш туры сызык;
3) асты почмак ыргаклы озын авыш туры сызык;
4) кечкенә овал;
5) аска төшкән озын авыш туры сызык;
6) ике башы да йомры ыргаклы кечкенә авыш туры сызык.

• Укытучы 1 нче элементны әйтә һәм пауза ясый, балалар яза; аннан кабат әйтә, пауза ясый, ә балалар үз-үзләрен тикшерә. Шул рәвешле калган элементлар белән эш оештырыла.

Укытучы үрнәге нигезендә үз-үзләрен тикшерәләр, хор белән элементларны «укыйлар», үз-үзләрен бәялиләр.

Бәяләү:

| | |
|---|---|
| 6 элемент та дөрес, төгәл язылган, кызыл юл дөрес, нокта,өтерләр дөрес куелган, ураштырылган | 5 балл |
| 4, 5 элемент һәм калган таләпләр үтәлгән | 4 балл |
| 6 элемент дөрес, калган таләпләрнең бер-икесе үтәлмәгән | 4 балл |
| 3 элемент һәм калган таләпләр үтәлгән | 3 балл |
| 2 элемент һәм калган таләпләрнең кайберләре, яки 0 элемент, ә калган таләпләр төгәл үтәлгән | 2 балл |

Δ 1) астан йомры ыргаклы кечкенә авыш туры сызык белән аска таба озын авыш туры сызык;

2) асты элмәкле озын авыш туры сызык белән кечкенә овал;

3) аста почмак ыргаклы өстән озын авыш туры сызык белән аска төшкән озын авыш туры сызык.

Искәрмә: Δ – бу эш укытучы карамагына куела; әгәр алдагы һәр дәресе гез максималь нәтиҗә биреп килгән булса, бу биремне дә башкара алачаклар

Δ текст белән эшченлекне бәяләү:

| | |
|---|---|
| 3 кушылма да дөрес, кызыл юл, 2 өтер һәм нокта дөрес урныштырылган | 5 балл |
| нинди дә булса 1 әр кимчелеге бар | 4 балл |
| 1 генә кушылма, кызыл юл, өтерләр, нокта дөрес | 3 балл |
| 2 кушылма дөрес, калган таләпләрнең кайсысыдыр төгәл түгел | 3 балл |
| калган очракларда | 2 балл |

**Иҗек диктанты.**

**Максат:** Иҗекләрне ишетеп язу күнекмәсе формалаштыру, хәрефләрне дөрес тоташтыру күнекмәләрен тикшерү**.**

Ау, әү, ум, ли, рә, нә, └ән, ар, └ри, зү.

( └ - шуннан кыскартырга мөмкин).

Диктант язу ысулы искә төшерелә:

1) Укытучы язарга тиешле барлык иҗекләрне дә укып чыга. Укучылар тыңлый (Искәрмә: укытучы пауза ясаган урынга иҗекләр арасына « , » куела. Беренче иҗек баш хәрефтән башлана, ахырда «нокта» куела).

2) Укытучы беренче иҗекне әйтә, укучылар ручкаларын дөрес итеп тотып, дөрес итеп утырып, дәфтәрне дөрес итеп куеп тыңлыйлар → иҗекләрне күзалдына китерәләр.

3) Укытучы тагын кабатлый, укучылар яза. Шул рәвешле һәр иҗек язылa.

4) Укытучы кабат укып чыга, укыучылар үз эшләрен тикшерәләр.

5) Укытучы үрнәк бирә. Бергәләп анализ ясыйлар, → үзбәя куялар.

Бәяләү:

Критерий:

| | |
|---|---|
| беренче иҗек баш хәрефтән | 1 балл |
| кызыл юл дөрес | 1 балл |
| иҗекләр дөрес | 1 әр балл (һәр иҗеккә 1 әр балл (10 иҗек алынса 10 балл, 6 иҗек - 6 балл) |
| иҗекләр арасы дөрес, өтер дөрес урнаштырылган | 10 иҗек - 9 ара → 9 балл<br>6 иҗек -5 ара → 5 балл |
| ахырда нокта дөрес урнаштырылган | 1 балл |
| хәрефләр тоташуы дөрес | 10 иҗек- 10 тоташу- 10 балл |
| хәрефләр үлчәме дөрес | 6 иҗек - 6 тоташу - 6 балл<br>ярдәмче юлда да язылган хәрефләр һәр хәрефкә 1 әр балл;<br>10 иҗек тә рәттән - 7 балл (ү-2; у-2; р-3);<br>6 иҗек тә рәттән - 4 балл (у-2; ү-1; р-1); |
| Максималь балл: | 39 (10 иҗек) яки 24<br>39 яки 24 балл - «5»<br>21-38 яки 13-23 балл -«4»<br>15-20 яки 7-12 балл - «3»<br>14-↓ яки 6-↓- балл - «2 |

## КҮЧЕРЕП ЯЗУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ ФОРМАЛАШТЫРУ

Күчереп язу ысулы укучыга берничә этапта өйрәтелә:

- әле укучы укырга өйрәнгәнче һәм элементлар белән эш барышында: игътибар белән карыйм → нинди элементлардан торуын ачыклыйм үрнәктәгечә күчереп язам→ үрнәк белән чагыштырам;

- иҗекләр белән эш барышында: игътибар белән карыйм →укыйм → истә калдырам → үз-үземә әйтәм → язам → үрнәк белән чагыштырам,

- сүзләр белән эш барышында: игътибар белән карыйм → укыйм → истә калдырам → үз-үземә иҗекләп әйтәм → язам,

- җөмләләр белән эш барышында: игътибар белән укыйм →җөмләне истә калдырам → язу темпыма бәйле рәвештә сүзләп әйтәм → язам,

- текст белән эш барышныда: текстны гөжләп укыйм. Кызыл юлларга игътибар итәм. Беренче җөмләне укыйм → истә калдырырга тырышам → әйтелеше белән язылышында аерма булган сүзләрне ачыклыйм → эчтән генә үз-үземә сүзләп әйтәм → язам (озын сүзләрне иҗекләп әйтәм). Аннан соң икенче җөмләне укыйм → истә калдырам → үз-үземә әйтеп яздырам.

Шул рәвешле абзацтагы калган җөмләләрне күчереп язам → текст белән чагыштырам. Икенче абзацны күчереп язам.

### Текстны контроль күчереп язу эшчәнлеген бәяләү

Тәкъдим ителгән текст (мисал өчен):

Табигатьтә

Көн кояшлы. Күл өсте тын. Илназ әтисе белән балык тота. Ул кармакка җим куя. Калкавычны.күзәтә.Әтисе улы белән горурлана.

Искәрмә: Контроль эшләрне анализлау һәм бәяләү өчен махсус 2 дәрес бирелә. Чөнки әлеге контроль эш ел буена алып барылган эшчәнлекнең сыйфат күрсәткече булып тора.

Анализ укучылар белән бергә алып оештырыла. Укучыларга махсус әзерләнгән таблица таратыла.

| Бәяләнергә тиешле махсус белем һәм күнекмәләр | Максималь балл | Гомуми балл |
|---|---|---|
| Текст исеме: юл уртасына язылган | 1 | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| баш хәрефтән башланган<br>ахырда нокта куелмаган | 1<br>1 | |
| Кызыл юл дөрес калдырылган | 1 | 1 |
| Поля унда дөрес калдырылган сул якта дөрес калдырылган | 1<br>1 | 2 |
| Җөмлә башы баш хәрефтән ахырда нокта куелган | 6 җ. 1 әр балл<br>6 җ. 1 әр балл | 12 |
| Сүзләр арасы дөрес калдырылган | 13 ара, 1 әр балл | 13 |
| Җөмләләр арасы дөрес калдырылган | 5 ара, 1 әр балл | 5 |
| Баш хәрефләр дөрес язылган (Т- 1, И- 1, К- 3, У- 1, Ә- 1; барысы 5 хәреф) | 5 хәреф,<br>1 әр балл | 5 |
| Юл хәрефләре дөрес язылган: а-12; б-4; в-1; е-5; з-2; и - 4; к - 8; л - 10; м - 2; н - 2; о-3; р-3; с-3; т-9; у-3; ч-1; ш-1; ь-1; ы-6; я-2; ә - 6; ү-2; җ- 1; ө-2; | 24 хәреф,<br>1 әр балл | 24 |
| Хәрефләрне тоташтыру | һәр хаталы тоташтыруга - 1 балл | |
| Гомуми күрсәткеч | | |

Алга таба пробелларны бетерү өстендәге эшчәнлекне дифференциаль һәм индивидуаль оештыру өчен:

1) укучыларның үзләреннән үзләренә эш билгеләт (тарату таблицасын кара - 2 нче кушымта);

2) эш дәфтәрләрен һәм таблицаларны җыеп ал, анализ яса, эш планлаштыр.

Махсус белем һәм күнекмәләргә билге:

60-65 балл - «5»

46-59 балл - «4»

30-45 балл - «3»

29-↓- балл - «2»

Гомумуку күнекмәләрен бәяләү юнәлешләре:

- Уку эшчәнлегенең формалашу дәрҗәсе

1) Үз эшенә анализ ясый беләме?

2) Үзбәясе адекватмы? (гаделме?)

3) Пробелларна бетерү юлларын дөрес билгеләгәнме?

• Уку эшчәнлеген оештыруга комачаулаучы фактор: ишетәме? (күңел «колагы» ничек?)

хәтере ничек? (белем, күнекмәләре тотрыклымы?)

игьтибарлылыгы (күңел күзе ) ничек?

а) начар булса:

Нәтиҗә: Кем гаепле?

Ни эшләргә? Нинди ашыгыч чара оештырырга һәм ничек?

б) яхшы булса:

Кем аркасында?

укучыларым... үзем....

Ничек бик яхшы итәргә

**Эшне оештыру һәм тикшерү, бәяләү методикасы**

• Текстны кат-кат гөжләтеп хор белән, эчтән укытабыз.

• Эчтәлеген ачыклыйбыз, сүзнең нәрсә турында баруы хакында әңгәмә оештырабыз.

• Текстны күчереп язу методикасын искә төшерәбез: нәрсә эшлибез, ничек эшлибез? дигән сорауларга җавап бирәбез.

• Бурычны аңлатабыз: хәзер балалар дәфтәрләрегезне дөрес итеп куегыз, ручкаларны дөрес итеп тотыгыз. Китапны җайлы итеп куегыз (балалар параллель башкара, укытучы һәркемне күздән ничерә). Класс тәмам әзер булгач:

Мин «башладык» диюгә яза башларбыз; «туктадык» диюгә ручкаларыгызны куярсыз, башлаган сүзегезне дә тәмамлап тормассыз.

Ручкаларыгызны куеп кабатлагыз әле, ничек эшләрбез?

Хор белән: «Башладык» диюгә күчереп яза башларбыз, «туктадык» диюгә ручкаларны куярбыз.

Дөрес итеп һәм тиз язарга әзерләнәбез. Пауза. Ручкаларны алдык. «Башладык», һәм укучылар 3 минут дәвамында язалар. Укытучы секундомер белән вакытны күзәтә, 3 минут узуга «туктадык» командасына ручкалар куела.

Башкарылган эшкә анализ-тикшерү оештырабыз:

Һәркем ничә хәреф язарга өлгерде? Санагыз (вакыт бирелә) Гади каләм белән поляга язып куегыз. Искәпкә нокталарна да кертегез.

Дөрес язылмаган һәм тоташтырылмаган хәрефләр, кызыл, юл, поля, сүзләр һәм җөмләләр арасының астына сызыгыз. Санагыз, поляга языгыз.

Барлык хәрефләр санынннан дөрес язылмаган һәм дөрес тоташтырылмаган хәрефләр санын алабыз. Килеп чыккан санны поляга язабыз һәм түгәрәкләп алабыз.

Дөрес күчерелгән хәрефләр саны 3 кә бүленә. Укучылар әле бүлә белми, укытучы тиз генә бүлеп, поляларына язып чыга.

Бәялибез:

25 һәм ↑ тамга - «5» (бик яхшы)

20-24 тамга - «4» (яхшы)

10-19 тамга - «3» (начар)

10-↓- тамга - «3» (начар)

Бик яхшы булсын өчен нәрсәләр өстендә эшләргә, кайсы эшләрне яхшыртырга? Вакыт бирелә, һәркем үз эшен анализлый. Берничә укучы үзенең камилләштерергә кирәкле күнекмәләрен әйтә. Һәркем үз-үзенә эш ала (Үз-үзенә сөйли).

Тырышып, дөрес итеп текстны күчереп язып бетерү өчен вакыт бирелә.

### 1 нче сыйныфта изложение

1 нче сыйныфта изложение язу әлифба чоры тәмамлангач башлана. Эчтәлекне бирү характеры ягыннан иң гади төре - тулы, җентекле, текстка якын итеп бәян итә белү күнекмәләре формалаштыру максат итеп куела. Сюжетлы текст – 3, 4 бәйләнешле җөмләне эченә алган текст кулланышка кирә. Әле беренче сыйныф укучыларының орфографик күнекмәләре формалашу чорын гына кичергәнлектән, алда үзләштерелгән күнекмәләрне актуальләштерү һәм камилләштерүне оештыру эшчәнлеген күрсәтмәлелек белән тәэмин итү һәм хаталарны кисәтү максаты белән текст электрон тактада бирелә.

Актуальләштерелә:

Текст бер-берсенә бәйләнеп килә торган җөмләләрдән тора. Текстта бер яки күбрәк абзац була. Һәр абзац кызыл юлдан башлана. Текстны укыганда Кызыл юл озын пауза белән белдерелә. Текстның исеме уртага баш хәрефтән языла, ахырда тыныш билгесе (“?”, “!”, “.” ) куелмый. Җөмләләр (баш хәрефтән башлана, ахырда тыныш билгесе (“?”, “!”, “.” ) куела. Текстны

укыганда җөмлә тәмамлану кызыл юл паузасыннан кыскарак пауза белән белдерелә.

Искәрмә: Бу күнекмәләр әлифба чорында “күчереп язу”, “ишетеп язу” эш төрләре аша танып белдерелә, үзләштерелә.

## 2 нче сыйныфта изложение

2нче сыйныфта тулы, җентекле, текстка якын итеп бәян итү бераз катлауландырыла - текстның композициясенә әһәмият бирелә башлый. Бик кечкенә күләмле вакыйганы эченә алган өзек алына.

Хикәяләү тибындагы текстларны куллану өстенлек итә, катнаш төр текстлар – тасвирлаулы хикәяләүгә нигезләнгән текстлар кулланыла башларга мөмкин.

## 3-4 нче сыйныфларда изложение

3-4 нче сыйныфларда текста кулланган тел-сурәтләү чараларына, сөйләм төгәллегенә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешенә, вакыйга яисә күренешләр бирелешенең эзлеклелегенә зур әһәмият бирү аша танып белү күнекмәләрен камилләштерү бурычы куела. Мондый тирәнлектәге эшчәнлек бәйләнешле сөйләм камиллеген һәм фикер эшчәнлеге үсешен тәэмин итә.

**Планлаштырылган нәтиҗәлелек:** Башлангыч сыйныфны тәмамлаган укучыда бирелгән план нигезендә текст төзи, текстагы төп фикерне аерып ала белү; текст төзегәндә төрле синтаксик калыпларны урынлы һәм уңышлы куллана белү; әдәби тел нормаларын дөрес кулланып үз текстын төзү – үз фикерен белдерә алу күнекмәсе тотрыклы формалашырга тиеш.

**Нәтиҗәдә** укучы “Изложение” дип аталган мәктәп жанрының нәрсә икәнен, текст материалына һәм эчтәлекне бирү характерына карап төрләрен үзләштерә, укучыда түбәндәге универсаль гамәлләр

- танып белү (познавательные) гамәле – “изложение” язу ысулын белү һәм кулалану, үз текстын модельләштерү;
- коммуникатив (тыңлый, ишетә, таләп ителгән яссылыкта – эчтәлекне бирү характерына карап, үз эшчәнлеген оештыра, үз фикерен белдерә белә) гамәлләр;
- регулятив (изложение язу этапларын мөстәкыйль кулланышка куя, үз эшен үзе тикшерә, икеләнгән урыннарда белем

чыганакларына – белешмә сүзлекләргә мөрәҗәгать итә белә) гамәлләр формалашуы өчен җирлек тудырыла

## 5-6 нчы сыйныфларда изложение

5 нче сыйныф һәм 6 нчы сыйныфның беренче яртысы ул башлангыч сыйныфларда үзләштерелергә тиешле махсус белем һәм күнекмәләрне камилләштерү, "ак тап – пробел"ларны бетерү чоры.

## 6-9 нчы сыйныфларда изложение

6-9 нчы сыйныфларда максатчан рәвештә сочинение элементы белән яки иҗади биремле изложениеләр язуга зур әһәмият бирелә. Иҗади биремнәрнең төрләрен барлыйк:

- изложение тексты ахырынача укылмый – укучыга мөстәкыйль рәвештә тәмамларга кушыла;
- изложение текстын кайсы да булса бер персонаж исеменнән бәян итәргә кушыла;
- изложение текстында сурәтләнгән вакыйгаларның заманын – грамматик форманы үзгәртергә кушыла (әйтик, текстта вакыйга үткән заманда бирелсә, укучыга аның күз алдында барган итеп – хәзерге заманда бәян итәргә кушыла);
- изложение текстын сыйфатлар яисә рәвешләр белән баетырга тәкъдим ителә;
- изложение текстын тасвирламалар белән баетырга, мисал өчен кайсы да булса бер персонажның я тышкы кыяфәтен, я холкын, я фикер агышын, я хисләре үстерелешен тасвирлау;
- изложение тексты геройларын чолгап алган пейзажны тасвирлау;
- текста сөйләнгән вакыйганы китереп чыгарган сәбәпне, яисә персонажны шундый адымга этәргән сәбәпне тасвирлау.

Шул рәвешле, һәр сыйныфта өйрәтү характерындагы һәм контроль характердагы изложениеләр оештырыла.

Димәк, татар теле һәм әдәбияты укытучысы башлангыч сыйныф укытучысы белән килешенеп дәвамчанлык принцибын гамәлгә куюны оештырырга; язма эшләрнең бар төрен колачлаган эшчәнлекне системалы итеп планлаштырырга, оештырга, бердәм дәүләт имтиханнарын сыйфатлы тапшырырлык итеп әзерләргә бурычлы.

## КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1. Концепция федеральных государственных образовательных стандартов общего образования / под ред. А. М. Кондакова, А. М. Кузнецова – М.: Просвещение, 2009.
2. Фундаментальное ядро содержания общего образования / под ред. В. В. Козлова, А. М. Кондакова. – М.: Просвещение, 2009.
3. Ожегов С.И. Толковый словарь русского языка/ Российская академия наук. Институт русского языка им. В. В. Виноградова. – М: Азбуковник, 1998.
4. Педагогический энциклопедический словарь / гл. ред. Б. М. Бим-Рад; редкол.: М. М. Безруких, В. А. Болотов, Л. С. Глебов и др. – М.: Большая Российская энциклопедия, 2002.
5. Русско-татарский словарь / под ред. Ф. А. Ганиева. 4-е изд., испр. – М.: ИНСАН, 1997.
6. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда, I том. – Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1977 ел; II том. – Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1979 ел; III том. – Казан: «Татарстан китап нәшрияты», 1981 ел.
7. Татарча-русча сүзлек: 2 томда, I-II том. – Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2007 ел.

# КУШЫМТАЛАР

Кушымта 1

**Әлифба чоры нәтиҗәлелегенә үзанализ, үзбәя өчен тарату материалы** Күчереп язган текст буенча үзеңнең ел буе үзләштергән белем һәм күнекмәләреңне бәялә, игътибарлы һәм гадел бул. Соңыннан укытучы да бәяләр.

| Син башкарган эшләр | Үз эшеңә бәя | | Укытучы бәясе |
|---|---|---|---|
| | ничек бәяләргә? | балл | |
| Текст исеме: юл уртасына язылганмы? баш хәрефтән башланганмы? ахырда нокта куелмаганмы? | әйе-1 балл; юк -0; | | |
| Кызыл юл дөрес калдырылганмы? | Һәр кызыл юлга берәр балл | | |
| Поля уң яктан дәрес калганмы? сул яктан дөрес калганмы? | әйе-1 балл; юк -0; | | |
| Җөмлә башы баш хәрефтән башланганмы? ахырда нокта куелганмы? | һәр баш хәрефкә 1 әр балл һәр куелган ноктага 1әр балл | | |
| Сүзләр арасы дөрес калдырылганмы? | һәр дөрес арага 1әр балл | | |
| Җөмләләр арасы дөрес калдырылганмы? | һәр дөрес арага 1әр балл | | |
| Баш хәрефләр дөрес язынганмы? Текст булган баш хәрефләрне һәм аларны санын яз (үрнәк: К - 3, У - 1) | һәр дөрес баш хәрефкә 1әр балл (һәр хәрефне бер генә тапкыр сана,5 тапкыр язсаң да) | | |
| Юл хәрефләре дөрес язылганмы? һәр хәрефнең текстагы санып күрсәт: а- б- ; в- г- ; д- ; е- ё- ; ж- з- ; и- ; й - к- ; л - м- ;н- ; о- п- ; р- с- ; т- ; у- ф- ; х- ц- ; ч- ; ш- щ-;ь- ъ - ;ы- ; ү- җ- ; ң- ; һ- | һәр дөрес юл хәрефенә 1 әр балл Искәрмә: а, берничә тапкыр кулланылган хәрефләрнең 1-2се кимчелекле булса да 1 әр балл Мисал: а - 12; әгәр 10сы дөрес икән - 1 балл | | |
| Барысы ничә балл куйдың? Сана һәм яз. | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Хәрефләрне дөрес тоташтыргансыңмы? Гади каләм белән текста дөрес тоташмаган урыннарның астына сыз һәм сана. Ничә урында, нинди хәрефләрне тоташтырганда хата ясагансың? | һәр дөрес тоташтырылмаган элемент өчен 1әр балл кимет | | |
| Гомуми күрсәткеч (дөрес эшләгән эшләргә куелган баллардан дөрес эшләмәгән эш балларын ал ) | | | |

Кайсы эшләрне тиешенчә эшли алмагансың? Ни өчен шулай булды икән? Кем гаепле? Алга таба өйдә һәм класста нәрсәләрне кабатларга теләр идең? Таблицада шул эшләрнең астына гади каләм белән сыз.

Кушымта 2

## Укучыларның коммуникатив компетентлылыгын бәяләү критерийлары

***Укучыларның коммуникатив компетентлылыгын бәяләү критерийлары***

| № п/п<br><br>Тәртип саны | **Компоненты коммуникативной компетенции** | Үзләштерелергә тиешле күнекмәләр<br><br>коммуникатив компетентлык күрсәткечләре | **Бәя / оценка** | | | | Искәрмә /<br><br>**примечание** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **«5» (%) навык/** автомат. күнекмә | **«4» (%) умение/** күнемә | **«3» (%) знает/** белә | **«2» (%) незнает/** белми | |
| 1. | Речевая **компетенции** | **Сөйләм компетентлылыгы** | | | | | |
| | **Диалогическая речь** | **Диалогик сөйләм күнекмәсе:** | | | | | |
| | *соответствие речевого акта заданной ситуации* | –сөйләмнең тәкъдим ителгән ситуациягә тәңгәллеге (ситуатив күнекмәсе) | | | | | |
| | *реактивность– своевременность и осмысленность реакции на реплику или на вопрос* | –реактивлык (куелган сорауны аңлый һәм үзвакытлы реплика белдерә); | | | | | *мимика, жестлар белән уңышлы җаваплар да уңай бәяләнде* |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | *апеллятивность– социально-корректная обращенность* | апеллятивлык (әңгәмәдешенә социаль корректлы итеп җавап бирә, сөйләм үрнәкләрен урынлы куллана белүе); | | | | | *әңгәмәдәш итеп таныш булган һәм таныш булмаган олы кеше, яшьтәш, кечерәк яшьтәге кешеләр алынды* |
| | *коммуникабельность– способность поддержать разговор путем развернутой реакции на высказывание собеседника, предложение новых тем, сюжет, поддерживающий диалог* | – коммуникабльлек күнекмәсе (җавап биреп кенә калмый, ә әңгәмәгә яңа төсмер, яңа сюжет кертеп җибәрә ала); | | | | | |
| | **Монологическая речь** | **Монологик сөйләм күнекмәсе:** | | | | | |
| | *уместно использует знакомые слова , фразы и предложения* | – исендә калган сүзләрне, җөмләләрне урынлы куллана; | | | | | |
| | *умело использует грамматические* | – грамматик конструкцияләрдән | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | *категории при составлении предложения* | файдаланып җөмләләр төзи; | | | | | |
| | *продуктивность речи, (умение донести свою мысль на татарском языке)* | – сөйләм продуктивлыгы (үз фикерен татарча җиткерә ала); | | | | | *сүзлекләрдән файдаланып фикерен татарча формалаштыруы да күнекмә буларак бәяләнә* |
| | *темп речи* | сөйләм темпы | | | | | |
| | **Сформированность умение понимания речи на слух** *(аудирование*) | **Ишетеп аңлау күнекмәсе:** | | | | | |
| | – перцевтивные (восприятие, узнование, понимание языковой – фонетической, лексической, грамматической информации прослушанного текста) действия | – перцевтив (моңарчы ишеткән текстны таный) | | | | | |
| | *– вычленение единиц* | – аудиотексттагы | | | | | *русчалы-* |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | *смысловой информации, выделение из текста главного и деталей* | төп фикерне аерып ала, аңлый | | | | | *татарчалы җавап та уңай бәяләнә* |
| | *– мнемические действия (формирование образа, узнование, опознавание в результате сличения с эталоном, хранящимся в памяти)* | – образлы итеп кабул итә ала, хәтердә тотрыклы саклый; | | | | | *образлы фикер үсеше өчен дәреслектә һәм эш дәфтәрләрендә рәсемнәр булу һәм текст алды рәсеме белән эшнең эшчәнлек алгоримпының бер элементы булуы уңай нәтиҗә бирә* |
| | *– моторные действия (проговривание, осуществляемое во внутренней речи)* | эчке сөйләм белән әйтә ала | | | | | |
| | **Сформированность умение чтения** | **Аңлы уку күнекмәсе:** | | | | | *Татар теленең үзенчәлекле авазларын әйтүдәге кимчелек исәпкә алынмады* |
| | *1) працесуальность (техника чтения )* | уку техникасы | | | | | |
| | *– чтение по слогам* | – иҗекләп укый («3» – белә); | | | | - | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | *–чтение словами* | – сүзләп укый ( «4» – күнекмәсе бар); | | | | | |
| | *– чтение синтагмами* | –синтагмалап укый («5» – автоматлашкан күнекмәгә ия) | | | | | |
| | *2) содержательный (понимание прочитанного)* | | | | | | |
| | *– понимание прчитанного* | –аңлап уку | | | | | |
| | *– умение извлечь содержательно-смысловой информации, подтекста* | мәгълүматның яшерелгән мәгънәсен таба белү | | | | | *бу туган телдә дә махсус әзерлек таләп итә торган күнекмә...* |
| | **Сформированность умение письменной речи** | **Язма сөйләм күнекмәсе:** | | | | | *Махсус методика* |
| | письменные ответы на вопросы;<br>составление и написание вопросов к тексту | сорауларга язма җавап бирү, текстка карата сораулар әзерләү һәм язу | | | | | *ярдәмендә тикшерелде* |
| | *списывание небольшого текста* | күчереп яза | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | *умение писать под диктовку* | ишетеп яза | | | | | |
| 2. | **Языковая компетенции** | ***Тел гыйлемендә компетентлылык*** | | | | | |
| | *овладение фонетическими языковыми средствами* | татар теленең үзенчәлекле авазларын үзләштерү күнекмәсе | | | | – | *иң кыен үзләштерелүче авазлар: ү, ә , ө* |
| | *Овладение грамматическими категориями* | Грамматик күнекмәләре (үзләштерү дәрәҗәсе): | | | | – | |
| | *– умение использовать модель предложения* | – җөмлә моделе | | | | – | |
| | *– особенности словообразования* | – сүз ясалышы үзенчәлеге | | | | – | |
| | *– речевые обороты* | –сөйләм үрнәкләре | | | | – | |
| 3. | **Социокультурная компетенция** | ***Социаль- мәдәни компетентлылык*** | | | | | |
| | *знание культуры, традиции* | *татар халкының мәдәниятын һәм гореф гадәтләрен белү* | | | | | *рус телендә дә аңлатып бирү мөмкинчелеге карала* |
| | *умение представить родную культуру в* | *үз милләтенең мәдәниятын* | | | | | *үз милләте мәдәниятын* |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | *диалоге культур* | *мәдәниятлар яссылыгында карый белү* | | | | | *белмәгән балалар бар, татар телен рус балалары гына өйрәнми бит...* |
| 4. | **Компенсаторная компетенция** | ***Компенсацияләү күнекмәсе*** | | | | | |
| | *умение выходить из положения в условиях дефицита языковых средств при получении и передачи информации* | *Сүз байлыгы җитмәгән очракта ситуациядән чыгу җаен таба белү күнекмәсе(төрле ым, хәрәкәт белән фикер белдерү)* | | | | | |
| 5. | **Учебно-познавательная компетенция (***овладение мыслительных операций) анализ, синтез, абстрагирование, конкретизация***,** *обобщение классификация, умение слушать и слышать* | ***Танып белү компетентлыгы*** *(анализ, синтез, абстракция, конкретлаштыру, гомумиләштерү, классификация ясау кебек фикерләү күнекмәләре; тыңлый һәм ишетү күнекмәләре үсеше)* | | | | | *языковое и смысловое прогнозирование аудиодиска, вычленение единиц смысловой информации, выделение изтекста главного и деталей* |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | *обеспечивает развития мыслительной деятелности* |

Критерии оценки и еденицы измерения / Бәяләү критерийләре һәм үлчәү берәмлеге:
«2» – белми (не знает);
«3» – белә (знает);
«4» – күнекмәсе бар (умеет);
«5» – автоматлашкан күнекмәгә ия (имеет навык)

**ЭЧТӘЛЕК**

ИЗЛОЖЕНИЕ ЯЗУГА ӘЗЕРЛЕК........................................................ 2

ИЗЛОЖЕНИЕ ТӨРЛӘРЕ ................................................................ 4

ӨЙРӘТҮ ХАРАКТЕРЫНДАГЫ ИЗЛОЖЕНИЕЛӘРНЕ ҮТКӘРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ.......................................................... 5

КОНТРОЛЬ ИЗЛОЖЕНИЕЛӘРНЕ ҮТКӘРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ.......... 6

ЯЗМА СӨЙЛӘМГӘ ӨЙРӘТҮ КАЙЧАН БАШЛАНА?.................. 7

БАЛАЛАРНЫҢ ЯЗУГА ӘЗЕРЛЕГЕН ТИКШЕРҮ МЕТОДИКАСЫ.................................................................. 10

ИШЕТЕП (ДИКТАНТ) ЯЗУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ ФОРМАЛАШТЫРУ .................................................... 12

КҮЧЕРЕП ЯЗУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ ФОРМАЛАШТЫРУ ................ 17

1 нче сыйныфта изложение.................................................. 20

2 нче сыйныфта изложение.................................................. 21

3-4 нче сыйныфларда изложение......................................... 21

5-6 нчы сыйныфларда изложение......................................... 22

КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ.................................. 23

КУШЫМТАЛАР ........................................................................ 24

# ИЗЛОЖЕНИЕ ЯЗУГА ӘЗЕРЛЕК

татар теле һәм әдәбияты буенча башлангыч гомуми һәм төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә куючы педагогик хезмәткәрләр өчен методик ярдәмлек

Корректура, компьютерная верстка, техническое редактирование
Гиниятуллина Р. С., Некратова А. В.

Форм.бум. 60х84 $^{1}/_{16}$. Гарнитура Times.
Усл.печ.л. 2,18.

Оригинал-макет подготовлен в редакционно-издательском отделе
Института развития образования Республики Татарстан
420015 Казань, Б.Красная, 68
Тел.:(843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
www.irort.ru, irort2011@gmail.com